**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ**
**РАЙОНЫ БАШКАРМА**
**КОМИТЕТЫ**

423740, Актаныш авылы, Ленин пр.,
17 нче йорт. Тел.3-02-22. Факс 3-13-44

**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
**АКТАНЫШСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

423740, село Актаныш, пр. Ленина,
дом 17. Тел. 3-02-22. Факс 3-13-44

**КАРАР**
26.10.2018

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
ПР-269

## Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 30 май аенда гамәлгә кергән “Актаныш муниципаль районының иҗтимагый торак комиссиясе” утырышына үзгәрешләр кертү турындагы № ПР-123 номерлы карары.

Россия Федерациясе Торак кодексы, «Татарстан Республикасында торак төзелешен үстерүгә дәүләт ярдәме турында» 2004 елның 27 декабрендәге 69-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасында социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ күпбалалы гаиләләрне торак белән тәэмин итү буенча өстәмә чаралар турында» 2005 елның 15 апрелендәге 190 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ күп балалы гаиләләрне торак белән тәэмин итү буенча өстәмә чаралар турында» , Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1.Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының «Актаныш муниципаль районының иҗтимагый торак комиссиясе турында» 2018 елның 30 маендагы ПР-123 номерлы карарының 1 нче кушымтасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2. **1.1, 2.1.6, 2.1.7, 4.7, 4.8, 5.1** пунктларында "2014-2017 елларга һәм 2020 елга кадәрге чорга авыл территорияләрен тотрыклы үстерү «федераль максатчан программасы" сүзләрен «2013-2020 елларга авыл хуҗалыгын үстерү һәм авыл хуҗалыгы продукциясе, чимал һәм азык-төлек базарларын җайга салу буенча дәүләт программасы» сүзләренә алмаштырырга.

2. Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 30 маенда гамәлгә кергән ПР-123 номерлы карары белән расланган Торак комиссиясе составына үзгәреш кертергә, кушымта нигезендә, яңа редакциядә бәян итәргә.

3. Әлеге карар «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге адрес буенча рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә: http://pravo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында түбәндәге адрес буенча: http:/aktanysh.tatarstan.ru.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Башкарма комитеты җитәкчесе И. Ш. Бариев